КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2018 ел, 8 август г.Казань № 647

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2014 – 2019 елларга Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтен һәм Татарстан Республикасында муниципаль хезмәтне үстерү» дәүләт программасын раслау турында» 2013 ел, 22 ноябрь, 910 нчы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2014 – 2019 елларга Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтен һәм Татарстан Республикасында муниципаль хезмәтне үстерү» дәүләт программасын раслау турында» 2013 ел, 22 ноябрь, 910 нчы карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 ел, 18 декабрь, 997 нче; 2015 ел, 17 апрель, 260 нчы; 2015 ел, 9 сентябрь, 659 нчы; 2015 ел, 8 октябрь, 753 нче; 2016 ел, 14 март, 139 нчы; 2016 ел, 26 октябрь, 785 нче; 2017 ел, 8 май, 264 нче; 2017 ел, 6 октябрь, 763 нче; 2017 ел, 20 октябрь, 799 нчы; 2018 ел, 4 май, 316 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

карарның исемендә һәм 1 пунктта «2014 – 2019» саннарын «2014 – 2021» саннарына алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган «2014 – 2019 елларга Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтен һәм Татарстан Республикасында муниципаль хезмәтне үстерү» дәүләт программасында (алга таба – Программа):

исемендә «2014 – 2019» саннарын «2014 – 2021» саннарына алмаштырырга;

Программа паспортында:

«Программаның исеме» юлында «2014 – 2019» саннарын «2014 – 2021» саннарына алмаштырырга;

«Программаны тормышка ашыру вакытлары» юлында «2014 – 2019» саннарын «2014 – 2021» саннарына алмаштырырга;

«Еллар буенча бүлеп, Программаны финанслау күләмнәре» юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | |
|---|---|
| «Еллар буенча бүлеп, Программаны финанслау күләмнәре | Программаны Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән финанслауның гомуми күләме 295 807,18 мең сум тәшкил итә, шул исәптән:<br>2014 елда – 31 487,6 мең сум;<br>2015 елда – 30 987,08 мең сум;<br>2016 елда – 32 137,9 мең сум;<br>2017 елда – 56 504,6 мең сум;<br>2018 елда – 37 735 мең сум;<br>2019 елда – 35 785 мең сум;<br>2020 елда – 35 585 мең сум;<br>2021 елда – 35 585 мең сум»; |

«Программаны тормышка ашырудан көтелә торган соңгы нәтиҗәләр» юлының беренче абзацында «2020 елга» сүзләрен «2021 елга» сүзләренә алмаштырырга;

Программаның II бүлегендәге уникенче абзацында «2014 – 2019» саннарын «2014 – 2021» саннарына алмаштырырга;

Программаның III бүлеген түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«III. Программаның ресурслар белән тәэмин ителешен нигезләү

Программа чаралары Татарстан Республикасы бюджеты исәбеннән тормышка ашырыла. 2014 – 2021 елларга Программаны финанслау күләме 295 807,18 мең сум тәшкил итә, шул исәптән:

2014 елда – 31 487,6 мең сум;
2015 елда – 30 987,08 мең сум;
2016 елда – 32 137,9 мең сум;
2017 елда – 56 504,6 мең сум;
2018 елда – 37 735 мең сум;
2019 елда – 35 785 мең сум;
2020 елда – 35 585 мең сум;
2021 елда – 35 585 мең сум».

Бюджет мөмкинлекләрен исәпкә алып, Программаны тормышка ашыруга юнәлтелгән акча күләмнәре чираттагы финанс елына Татарстан Республикасы бюджеты проектын эшләгәндә тәгаенләнә.»;

Программаның V бүлегендәге тугызынчы абзацта «2020 елга» сүзләрен «2021 елга» сүзләренә алмаштырырга;

Программага 1 нче һәм 2 нче кушымталарны яңа редакциядә бәян итәргә (карарга теркәләләр).

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин